КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

02.06.2025　　№65-п

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының «Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсын үткәрү турында» 2021 елның 12 августындагы 120-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

«Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы карары белән расланган «Җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» Татарстан Республикасы дәүләт программасында каралган «Халык арасында наркоманияне профилактикалау» процесс чаралары комплексын гамәлгә ашыру кысаларында БОЕРЫК БИРӘМ:

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының «Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсын үткәрү турында» 2021 елның 12 августындагы 120-п номерлы боерыгына («Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2024 елның 27 мартындагы 56-п номерлы боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта “җитәкче” сүзен “җитәкченең беренче” сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән боерык нигезендә расланган сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән социаль реклама конкурсын үткәрү турындагы Нигезләмәдә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

«Социаль челтәрләргә урнаштыру өчен наркотикларга каршы реклама видеороligына иң яхшы сценарий» (1, 2 урын).

«Наркотикларга каршы һәм /яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы мем, рәсемнәр сериясе» (1, 2 урын).

«Наркотикларга каршы һәм /яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы иң яхшы текст, шигырь, җыр, канатлы гыйбарә, шигарь» (1, 2, 3 урын).

«Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга өлеш керткән өчен» махсус номинация (1,2, 3, 4 урын).»;

5.2 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) конкурс эшләре – наркотикларга каршы юнәлештәге видеоролик сценарийлары, наркотикларга каршы һәм /яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы мем, рәсемнәр сериясе, наркотикларга каршы һәм /яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы иң яхшы шигырь, җыр текст, канатлы гыйбарә, шигарь. Конкурс эшләрен сәнгатьле тәкъдим итү максатыннан өстәмә рәвештә иллюстрацияләр, дизайн-макетлар, видео һ.б. тапшырылырга мөмкин.

Видеороликның жанры (интервью, репортаж, видеоклип, мультфильм һәм башкалар) катнашучылар тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

Конкурска тапшырылган видеороликларның сценарие түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

күләме: 1  - 5 бит басма текст (Times New Roman шрифты, 14 кегль, юл арасы 1,5 интервал);

структурасы: фикерне ачып бирү, вакыйгаларны тасвирлау, персонажлар, диалоглар;

өстәмә рәвештә кадрлар тупланмасы, иллюстрацияләр, презентация материаллары кабул ителә.

Конкурска тапшырылган мемнар яисә рәсемнәр түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш::

саны: бер сериядә кимендә 3 иң күбе 10 мем/рәсем;

форматы: JPEG, PNG, GIF, кимендә 800x600 пиксель;

һәрбер мем/рәсем буенча төп фикерне кыскача гына аңлатма  (100 сүзгә кадәр) бирелә.

Конкурска тапшырылган җыр тексты, шигырь, канатлы гыйбарә, шигарь түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

шигырь: күләме иң күбе 2 басма бит (Times New Roman шрифты, 14 кегль);

җыр тексты: автор сүзләре һәм ноталар/аккордлар;

канатлы гыйбарә, шигарь: конкурс  идеясен кыска һәм ачык белдерү (күләме 20 сүзгә кадәр).

Барлык текстларга рәсем, иллюстрация, инфографика өстәп бирергә мөмкин.»;

5.2 пунктның «в» пунктчасында:

икенче абзацта «(күчермә)» сүзен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «(күчермә)» сүзен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «(күчермә)» сүзен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «(күчермә)» сүзен төшереп калдырырга;

5.2 пунктның «г» пунктчасында:

икенче абзацта «(күчермә)» сүзен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «ММЧ редакциясе уставы яисә аны алмаштыра торган шартнамә күчермәсе» сүзләрен «ММЧ редакциясе уставы яисә аны алмаштыра торган шартнамә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «документның күчермәсе» сүзләрен «документ» сүзенә алмаштырырга;

5.2 пунктның «д» пунктчасындагы икенче абзацта «(күчермә)» сүзен төшереп калдырырга;

5.2 пунктның «е» пунктчасындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктның «б» - «е» пунктчаларында күрсәтелгән документлар, кәгазь документларның электрон рәвешләре буларак, ачык форматта, гамәлдәге программалар белән тәэмин ителгән җайланмалар аша тулысынча яки аерым өлешләрен карау мөмкинлеге булган килеш konkurs_zozh@mail.ru электрон почта адресына җибәрелә. Бу абзацта күрсәтелгән документлар шифр ярдәмендә яисә эчтәлек белән танышу өчен лицензияле яки башка килешү төзеп, сатып алына торган өстәмә программалар таләп ителә торган башка чаралар ярдәмендә сакланган булырга тиеш түгел. Белешмәләр өчен телефон: 8 (843) 570-31-12.»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Конкурс эшләре анкетада күрсәтелгән саклау ресурсларына актив сылтама бирелеп, Россия Федерациясе дәүләт телендә, Россия Федерациясе составындагы республикаларның дәүләт телләрендә, Россия Федерациясе халыклары телләрендә тапшырыла. Конкурс эшләре Россия Федерациясе составындагы республикаларның дәүләт телләрендә, Россия Федерациясе халыклары телләрендә, татар теленнән тыш, тапшырылган очракта, материалларның рус теленә тәрҗемәсе дә бирелә, ул катнашучы җитәкчесенең имзасы һәм, булган очракта, мөһере белән таныклана.»;

5.5 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

5.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.9. Гариза бирүчегә Конкурста катнашырга рөхсәт бирелмәү турында Агентлыкның җитәкчесе имзалаган һәм анкетада күрсәтелгән электрон почта адресына юлланган хат белән әлеге Нигезләмәнең 5.2 пунктында каралган документлар алынган көннән башлап биш эш көне эчендә хәбәр ителә.»;

8.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.3. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

| N т/б | Номинация | Урын | Сумма |
|---|---|---|---|
| 1 | «Социаль челтәрләргә урнаштыру өчен наркотикларга каршы реклама видеороликгына иң яхшы сценарий» | 1 урын | 30,0 мең сум |
| | | 2 урын | 20,0 мең сум |
| 2 | «Наркотикларга каршы һәм /яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы мем, рәсемнәр сериясе» | 1 урын | 30,0 мең сум |
| | | 2 урын | 20,0 мең сум |
| 3 | «Наркотикларга каршы һәм /яисә сәламәт яшәү рәвешен пропагандалаучы иң яхшы текст, шигырь, җыр, канатлы гыйбарә, шигарь» | 1 урын | 30,0 мең сум |
| | | 2 урын | 25,0 мең сум |
| | | 3 урын | 15,0 мең сум |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | «Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга өлеш керткән өчен» махсус номинация | 1 урын | 30,0 мең сум |
| | | 2 урын | 25,0 мең сум |
| | | 3 урын | 20,0 мең сум |
| | | 4 урын | 15,0 мең сум.» |

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән
социаль реклама конкурсын үткәрү
турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта

(тәкъдим ителә торган форма)

| Конкурста катнашу өчен анкета-гариза | |
|---|---|
| Гариза бирүче (ММЧ; авторның, авторлар коллективының Ф.И.Ат. ис.*) | |
| Номинация исеме | |
| Конкурска тәкъдим ителгән эшнең исеме | |
| Аннотация | |
| Конкурс эше урнаштырылган саклау ресурсы | |
| Адрес | |
| Телефон | |
| Электрон почта | |
| Гариза бирүченең банк реквизитлары (банк исеме, ИНН һәм КПП, БИК, исәп-хисап счеты номеры | |
| ИНН (физик затлар өчен) | |
| СНИЛС (физик затлар өчен) | |

Түбәндәгеләрне раслыйм:

Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән конкурска тәкъдим ителгән конкурс материалларында өченче затларның авторлык һәм башка хокукларын боза торган материаллар юк;

«Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты статусым юк;

авторлар коллективы составында «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил статусына ия затлар юк**.

***** Атасының исеме булган очракта күрсәтелә

** Гариза авторлар коллективы тарафыннан бирелгән очракта күрсәтелә

Дата _________________

Имза _____________________ ____________________________

(фамилия)»

Җитәкче А.С. Сәлимгәрәев